| | | |
|---|---|---|
| **СОВЕТ РОДНИКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ АЙОНЫНЫҢ РОДНИКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**с. Родники**

**08.10.2019** **№ 112**

**“Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге территорисенә керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы” нигезләмәне раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Родники авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә

**Родники авыл җирлеге советы карар итте :**

1.Бирелгән Кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге территорисенә керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы» нигезләмәне яңа редакциядә расларга.

2.Түбәндәге карарлар үз көчләрен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 сентябрендәге 84 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында “гы нигезләмәсен раслау турындагы карары»;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 июнендә кабул ителгән 107 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 сентябрендәге 84 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында " гы карары.

Әлеге карарны Родники авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Родники авыл җирлеге башлыгы , Совет Рәисе , Е.А. Яковлева**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
советының 08.10. 2019 ел
№ 112 лы карарына кушымта .

**“Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ,
Родники авыл җирлеге территорисенә керүче торак пунктларда ,гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы
Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә(алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясы һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Родники авыл җирлеге Уставының 23 нче статьясы нигезендә эшләнде.

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Халык җыены гомуми рәвештә,тигез хокуклы турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пунктта яшәүчеләр, даими яки нигездә аның территориясендә яшәүчеләр, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия кешеләр катнаша ала.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ихтыяри һәм ирекле.

1.4. Гражданнар,җыенда шәхсән үзе катнаша, һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Халык җыены халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатыннан үткәрелә.

1.6. Әгәр әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, Устав нигезендә гражданнар җыены этаплап уздырыла.

Гражданнар җыены вәкаләтләре

1.7. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

күрсәтелгән торак пункт, җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, торак пункт шул җирлек территориясендә булганда, башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүне үз эченә алган җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

Совет вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә әлеге җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

Совет вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә сайлау хокукына ия булган халык саны 100 дән артык кеше булса, җирлек советын төзү, аның санын һәм вәкаләтләре чиген билгеләү буенча;

Совет вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча фикер алышулар;

җирлек составына керүче , яисә Алексеевск муниципаль районы чикләрендә урнашкан торак пунктта үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;

авыл җирлегенең халык тыгызлыгы түбән булуы, бару юллары кыенлыклар тудырганда, яки халык саны 100 кешедән артмаган очракта, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча .;

авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл җирлеге старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча фикер алышу ;

авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү

1.8. Җыенны үткәрү авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Җыенга әзерлек һәм аны үткәрү белән бәйле чыгымнар җирлек бюджеты хисабына башкарыла.

2. Халык җыенын чакыру тәртибе.
Халык җыены үткәрү инициативасы

2.1. Халык җыенын торак пунктта үткәрү инициативасы:

- җирлек башлыгына;

- сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия булган 10 кешедән дә ким булмаган кешеләр группасы, торак пунктта яшәүчеләр (ягъни Россия Федерациясенең эшкә сәләтле гражданнары), даими яки күбесенчә торак пункт территориясендә яшәүчеләр, яшәү урыны буенча бу торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән кешеләр , шулай ук торак пункт территориясендә даими яисә күбесенчә яшәүче һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукка ия булган чит ил гражданнары.

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы куллар куелган кәгазь (1 нче кушымта) яисә инициатив төркем җыелышының беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә , һәм анда җыен үткәрү инициативасын күрсәтү турындагы карар кабул ителүе ,һәм тагын:

гражданнар җыенына чыгарыла торган сораулар;

гражданнар җыенын үткәрүнең тәкъдим ителгән вакыты;

гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр гражданинның паспорт сериясе һәм номеры, яшәү урыны, аның имзасы һәм имзасын кертү датасы.

2.3. Җыенны үткәрү инициативасын хуплау өчен җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, даими яки нигездә яшәүче, торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саныннан 5 процентны тәшкил итә, ләкин 10 имзадан ким була алмый. .

2.4. Кул куелган кәгазьләр , раслау вакытын куеп, фамилия, атасының исеме, туган көне, паспортның номеры һәм сериясе, яшәү урыны күрсәтеп имзалар җыючы зат тарафыннан раслана,һәм җирлек башлыгына җибәрелә.

Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены җирлек Советы карары белән (2 нче кушымта), ә җирлек башлыгы инициативасы белән – җирлек башлыгы карары белән (3 нче кушымта)барлык кирәкле документлар кергән көннән 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Авыл җирлеге башлыгы яисә Советның гражданнар җыенын үткәрүгә, максатка ярашлы түгел дип каршы төшәргә хаклары юк.

2.7. Гражданнар җыенына чыгарылган сорау (гражданнар җыены этаплары) Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәскә тиеш. Халык җыенына куелган сорау,күп төрле бәян итүләр тудырмыйча гына җавап бирергә мөмкинлек бирә торган итеп формалаштырылырга, ягъни аңа бары тик бертөсле җавап кына бирергә мөмкин булырга тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү, аны күчерү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе җирлек уставы белән билгеләнә һәм муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирлек Уставында каралган тәртиптә басылып чыга (халыкка җиткерелә).

Авыл җирлеге башлыгы карарында яки Советның гражданнар җыенын үткәрү турындагы карарында түбәндәгеләр күрсәтелә: халык җыенына чыгарыла торган мәсьәлә; гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы-авыл җирлеге органының структур бүлекчәсе турында мәгълүмат.

2.9. Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы җирлек органының структур бүлекчәсе(җирлек башкарма комитеты), җирлек башлыгы карары яки Гражданнар җыенын үткәрү турындагы Совет карары нигезендә сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлеген төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; муниципаль берәмлек халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыенына башка төрле ысуллар белән хәбәр итә (4 нче кушымта).

Авыл җирлеге башкарма комитеты халык җыены үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Гражданнар җыенын этаплап үткәргәндә, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү, халык җыенын үткәрү датасын билгеләү ,территориаль, вакытлы билгеләр, шулай ук башка очракларда мөмкин.

2.9.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә (5,6 нчы кушымталар).

2.9.3. Торак пунктта яшәүчеләргә халык җыены(гражданнар җыены этаплары) вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Гражданнар җыенын(гражданнар җыены этапларын) билгеләү турындагы карар, гражданнар җыенын(гражданнар җыены этапларын) үткәрү вакыты һәм урыны, гражданнар җыены (гражданнар җыены этапларын) үткәрелгән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш.Гражданнар җыенының этапларын үткәрү вакыты һәм урыны , халык җыенын билгеләү турындагы карарда күрсәтелә.

2.9.4.Гражданнар җыенын этаплап уздыру очрагында, җыен этаплап ,гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да соңга калмыйча уздырыла .

Халык җыены этапларын күчергәндә, гражданнар җыенын күчерү турындагы карар җыенны уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, җыенны уздыруга закон нигезендә җыен үткәрелергә тиеш булган бер ай дәвамындагы чорны исәпкә алып билгеләнә .

2.9.5. 2.9 нчы пункт нигезендә һәр катнашучы гражданнар җыенына 5 көннән дә соңга калмыйча ,муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсендә, гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга , аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турындагы нигезләмә нигезендә, халык җыенын үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Халык җыенын уздыру датасы ,билгеләнгән датага кадәр ,10 көннән дә соңга калмыйча күчерү турында карар кабул ителергә тиеш.

## 3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1.Җыенга килгән гражданнар, торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән, һәм сайлау хокукына ия булган кешеләр, җирлек башлыгының вәкаләтле заты тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2.Җыенда хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан башка катнашырга теләк белдергән башка гражданнар ,төрле оешма җитәкчеләре әгәр җыенда тикшерелә торган мәсьәләләрне хәл итү аларның эшчәнлекләре белән бәйле булса, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга мөмкин.

3.3. Сайлау хокукына ия булган ,торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче кеше теркәлергә һәм авыл җирлеге башлыгы тарафыннан җыенга кертелергә мөмкин

3.4. Язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) раслау булып гражданинның шәхесен раслаучы документның булуы санала (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һәм башкалар булырга мөмкин.)

3.5. Гражданнар җыенына, анда сайлау хокукына ия булган ,торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда ,хокукый көчкә ия була. Кворум булмаганда, халык җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү җирлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта халык җыены халык җыенын

үткәрү билгеләнгәннән көннән, ун көннән дә соңга калмыйча үткәрелергә тиеш.

3.6. Гражданнар җыены этаплап уздырылган очракта, гражданнар җыены җыенның аерым этапларында кеше күпме килгән очракта да хокуклы, аннан соң барлык уздырылган этаплар йомгаклары буенча тавышларны санап, ягъни мондый җыен бердәм булып кала.

3.7. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә.

3.8.Гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга яшерен тавыш бирүне уздырганда тавыш бирү өчен бюллетень (7 нче кушымта) бирелә.

3.9. Гражданнар җыенында авыл җирлеге башлыгы яисә ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.10. Гражданнар җыены Сәркатипне һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны өч кешедән ким була алмый.

Рәислек итүче Хисап комиссиясенә керә алмый.

Хисап комиссиясе:

1) халык җыенына килгән халыкның теркәлүен, кирәк булган очракта, аларның халык җыенында катнашу хокуклары дөреслеген тикшерә;
2) 2) гражданнар җыенының кворумын билгели(гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш));
3) тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;
4) 4) тавышларны саный һәм тавыш бирүгә йомгак ясый(гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш);
5) тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзи (гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча);
6) рәислеккә тавыш бирү нәтиҗәләре белән материаллар (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнар исемлеге) тапшыра.

3.11. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, җирлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелә ала. Көн тәртибенә җыенның инициаторлары тарафыннан кертелгән сораулар мәҗбүри рәвештә кертелә. Күрсәтелгән мәсьәләләр беренче чиратта карала. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турында карар, әгәр аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.12. Этаплап уздырылучы гражданнар җыены вакытында шулай ук авыл җирлеге башлыгы яисә теркәлгән катнашучылардан, ачык рәвештә,күпчелек тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат, рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.13. Гражданнарның этаплы җыенында тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены этабында (вариант буларак) кабул ителә: формасы гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә белән билгеләнә).

3.14. Гражданнар җыенын уздыру этапларының һәркайсында,хисап комиссиясе арасыннан гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча хисап комиссиясенең бер әгъзасы сайлана.Алар кворумны һәм йомгаклау тавышларын санаганда комиссия составында эшләячәк.

3.15. Җыен рәислек итүче тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртипне хуплый, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.16. Гражданнар җыенында сәркәтип тарафыннан беркетмә алып барыла, анда: халык җыенын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны күрсәтелә(8 нче кушымта) .

3.17. Халык җыенын этаплап уздырганда гражданнар Җыенының һәр этабында беркетмәләр (9,10 нчы кушымталар) алып барыла, алар алга таба гражданнар Җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча җыенның бер йомгаклау беркетмәсенә (11 нче кушымта), шулай ук хисап комиссиясе беркетмәләренә (12,13 нче кушымталар) тутырыла, алар шулай ук гражданнар Җыенының һәр этабында тавышларны санау нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең бер йомгаклау беркетмәсенә (14 нче номерлы беркетмә) тутырыла.

3.18. Гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларының датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны турында белешмәләр, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең йомгаклау нәтиҗәләре була. Җирлек башлыгы кул куя торган йомгаклау беркетмәсе ,гражданнар җыены карарын рәсмиләштерү өчен нигез булып тора.

3.19. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче зат, җыен секретаре кул куя һәм җирлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге теркәлә.

3.20. Гражданнар Җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча Хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, үткәрелгән этаплар саны, халык җыеннарының үткәрелгән этаплары буенча хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, алар өчен бирелгән тавышларның гомуми саны, аңа каршы тавышларның гомуми саны күрсәтелә.

1.21. Йомгаклау беркетмәсенә хисап комиссиясе рәисе һәм хисап комиссиясе әгъзалары кул куя һәм җирлек башлыгына тапшырыла.

## 4. Халык җыены карарлары

4.1. Әгәр сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы яклап тавыш бирсәләр,гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала, .

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, җирлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның җирлек уставы белән билгеләнгән вәкаләтләрне чикләү нигезендә үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар ,җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә мөмкин яки суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш һәм муниципаль хокукый актлар таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә.

4.6 . Әгәр торак пунктта яшәүчеләрне турыдан-туры ихтыярый белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (бастырып чыгару), күрсәтелгән актны кабул итү (бастырып чыгару) компетенциясенә керә торган җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән соң 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

Гражданнар җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарлар үтәлмәгән очракта,закон нигезендә җаваплылыкка тартылу каралган.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Родники авыл җирлеге башлыгы , Совет Рәисе Е.А. Яковлева**

“Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы Родники авыл
җирлеге территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
урындагы” нигезләмәгә
1нче номерлы кушымта

ЯЗЫЛУ КӘГАЗЕ

Без, түбәндәгеләр, _------------- муниципаль районы_ _ _ _ җирлеге ---------торак пунктында _ _ _ _ ------------------------------------------------------------

сорау формулировкасы белән халык җыены үткәрү инициативасын хуплыйбыз______________________________________________________________

(гражданнар җыенын үткәрү вакыты

________________________________________________________________________________

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу вакыты | Адресы,торган урыны | Паспортның сериясе, номеры я алыштыручы док-ң | Кул кую вакыты | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Язылу кәгазен таныклыйм ____________________________________

1. Фамилиям, исемем, әтинең исеме, туган көнем.

____________________________________________________________________

имзалар җыючы затның яшәү урыны, паспортның сериясе һәм номеры яки аны алмаштыручы документ

____________________ (имза һәм дата)

“Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы”
нигезләмәгә
2 нче номерлы кушымта

**Гражданнар җыены инициатив төркем**
**ихтияры белән чакырылган очракта**

**______ муниципаль районы**
**- -------------------җирлегенең _ _ _**
**үзара салым акчаларын кертү**
**һәм алардан файдалану мәсьәләсе**
**турында халык җыенын билгеләү турындагы**
**КАРАРЫ**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 28.07.2004 ел, № 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы, --------авыл җирлеге Уставының .......статьясы нигезендә

**-----------------авыл җирлеге советы карар итте :**

1.------------муниципаль районы -------- җирлеге-------- торак пунктында 20** елның -- ае.көне. 00 сәгать 00 минутта .Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын үткәрергә.

2. ------------муниципаль районы -------- җирлеге-------- торак пунктында 20** елның -- ае.көне. 00 сәгать 00 минутта .Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә җибәрү максатында ---------муниципаль районы -----------------җирлеге териториясендә 20** елда *** сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән,балигъ булган затлардан,кайбер азат ителүчеләрдән кала(азат ителүчеләрне күрсәтергә)җыюга сез ризамы?

» ӘЙЕ " КАРШЫ «»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ көн эчендә игълан итәргә.
Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Родники авыл җирлеге башлыгы ,**
**Совет Рәисе** **Е.А. Яковлева**

“Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы”
нигезләмәгә
3 нче номерлы кушымта

**Муниципаль берәмлек башлыгы карары**

**--------- муниципаль районының**
**--------җирлеге территориясендә**
**үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын билгеләү турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль район җирлегенең Уставының *статьясы нигезендә

**1. Карар бирәм:**

1. --------- муниципаль районының --------җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 20** елның ** ноябре көнне **сәг** минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган тәбәндәге мәсьәләне расларга: Җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә җибәрү максатында --------- муниципаль районы ----------------җирлеге териториясендә 20** елда *** сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән,балигъ булган затлардан,кайбер азат ителүчеләрдән кала(азат ителүчеләрне күрсәтергә)җыюга сез ризамы?

“ ӘЙЕ " КАРШЫ”

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып ___ көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

**Муниципаль район башлыгы** _____________ Ф.И.Аи________

“Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы”
нигезләмәгә
4 нче номерлы кушымта

ИСЕМЛЕК

___________________ муниципаль районы
____________ _____________________ яшәүче ___________
(торак пункт исеме) (җирлек исеме)
______________________________сайлау хокукына ия гражданнар

«___» _________________ 20___ ел

| №№ т.б | Фамилиясе, исеме, Атасының исеме | Туган елы (18 яшьтә-туган ае, көне) | Яшәү урыны, адресы | Паспорт сериясе,номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ ______________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)
Халык җыены секретаре _________ ______________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

“Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы”
нигезләмәгә
5 нче номерлы кушымта

**Гражданнар җыены**
**инициатив төркем инициативасы белән**
**үткәрелгән очракта**

## КАРАР

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча ---------------- муниципаль районы------------- җирлеге _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, җирлекнең Уставының *статьясы нигезендә

**-----------авыл җирлеге карар итте:**

1. --------- муниципаль районының --------җирлеге территориясендәге --------- торак пунктында үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 20** елның ** ноябре көнне **сәг** минутта гражданнар җыенының 1 нче этабын билгеләргә.
2. --------- муниципаль районының --------җирлеге территориясендәге --------- торак пунктында үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 20** елның ** ноябре көнне **сәг** минутта гражданнар җыенын 2 нче этабын билгеләргә.

**3.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү (территориаль, вакытлыча яки башка билге буенча) тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә.**
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә җибәрү максатында --------- муниципаль районы -----------------җирлеге територриясендә 20** елда *** сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән,балигъ булган затлардан,кайбер азат ителүчеләрдән кала(азат ителүчеләрне күрсәтергә)җыюга сез ризамы?

“ ӘЙЕ " КАРШЫ”

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ көн эчендә игълан итәргә.

Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Родники авыл җирлеге башлыгы ,**
**Совет Рәисе** **Е.А. Яковлева**

“Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы” нигезләмәгә

6 нчы номерлы кушымта

**Гражданнар җыенын муниципаль
берәмлек башлыгы
инициативасы белән
этаплап үткәргән очракта**

# Муниципаль берәмлек башлыгы карары

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча ---------------- муниципаль районы------------- җирлеге _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, җирлекнең Уставының статьясы нигезендә ,

**Карар бирәм:**

1. --------- муниципаль районының --------җирлеге территориясендәге --------- торак пунктында үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 20** елның ** ноябре көнне **сәг** минутта гражданнар җыенының 1 нче этабын билгеләргә.
2. --------- муниципаль районының --------җирлеге территориясендәге --------- торак пунктында үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 20** елның ** ноябре көнне **сәг** минутта гражданнар җыенын 2 нче этабын билгеләргә.

**3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе (территориаль, вакытлыча яки башка билгеләр буенча) муниципаль берәмлек башлыгының гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарында күрсәтелә.**
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә җибәрү максатында ---------- муниципаль районы -----------------җирлеге територичсендә 20** елда *** сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән,балигъ булган затлардан,кайбер азат ителүчеләрдән кала(азат ителүчеләрне күрсәтергә)җыюга сез ризамы?

“ ӘЙЕ " КАРШЫ”

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып ___ көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

**Муниципаль берщмлек башлыгы , Совет Рәисе**

**Е.А. Яковлева**

“Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы” нигезләмәгә

7 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге территорисендә гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану турындагы соравына яшерен тавыш бирү өчен

**БЮЛЛЕТЕНЬ**

| | | |
|---|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә куелган мәсьәләнең эчтәлеге | « Әйе» | ☐ |
| | «Юк» | ☐ |
| | | |

“Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы” нигезләмәгә

8 нче номерлы кушымта

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ ПРОТОКОЛЫ**

_______________________________________________

(торак пункт исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут№ _____

Булдылар _____________________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Халык җыенында рәислек итүче
_________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Халык җыены секретаре ______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ::**

1.
2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:**

1. Иванова Светлана Ивановна-ФАП мөдире

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

**ҖЫЕННЫҢ СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыенның секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Секретарь итеп ******сайлау тәгьдиме бар-Ф.И.Аи,эш урыны.
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп Ф.И.Аи һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар:
1. Иванов Иван Иванович -
2. Петрова Полина Петр Кызы –

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

**КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ : ( Вариант: тавыш бирү формасы гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә белән билгеләнә)**

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим яңгырады.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә))

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Хәл иттеләр:** (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: " Яклап" -____.
"Каршы» -____.
Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә))

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Хәл иттеләр:** (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: "Әйе" -___.
"Каршы» -____.

Карар ________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ _________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Халык җыены секретаре _________ _________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл жирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы” нигезләмәгә

9 нчы номерлы кушымта

**Гражданнар җыенын этаплап үткәргән очракта**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ ПРОТОКОЛЫ**

______________________________________________________

(торак пункт исеме)

«___» ____________ 20__ года 00 часов 00 минут№ __1___

Булдылар ____________________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Халык җыенында рәислек итүче
_______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Халык җыены секретаре ________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ::**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:** .

2. Иванова Светлана Ивановна-ФАП мөдире

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

**ҖЫЕННЫҢ СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** Җыенның секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Секретарь итеп ******сайлау тәгьдиме бар-Ф.И.Аи,эш урыны.
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп Ф.И Аи һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар:
3. Иванов Иван Иванович -
4. Петрова Полина Петр Кызы –
һ.б.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

_ _ _ _ _ _ _
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

**КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ : ( вариант: тавыш бирү формасы гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә белән билгеләнә)**

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим яңгырады.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**

______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә))

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**Хәл иттеләр: (карар эчтәлеге)**

Тавыш бирү нәтиҗәләре: "Әйе" -___.
"Каршы» -____.

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**

______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә))

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Хәл иттеләр: (карар эчтәлеге)**

Тавыш бирү нәтиҗәләре: "Әйе" -___.
"Каршы» -____.

**Рәислек итүче: йомгаклау карарының нәтиҗәсе гражданнар Җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча җирлекнең_ _ Уставы нигезендә рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка игълан ителәчәк).**

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ _________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Халык җыены секретаре _________ _________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы" нигезләмәгә

10 нчы номерлы кушымта

**Гражданнар җыенын этаплап үткәргән очракта**

**Халык җыенының икенче этабы протоколы (һ. б.))**

_______________________________________________
(торак пункт исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут № _2___

Булдылар ______________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Халык җыенында рәислек итүче
_______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Халык җыены секретаре ______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ::**
1.
2.

**Халык җыенында рәислек итүче сайлана:**

3. Иванова Светлана Ивановна-ФАП мөдире

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

**ҖЫЕННЫҢ СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыенның секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Секретарь итеп ******сайлау тәгьдиме бар-Ф.И.Аи,эш урыны.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

## ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

**Рәислек итүче:** гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ФИО һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар:

5. Иванов Иван Иванович -
6. Петрова Полина Петр Кызы –

һ.б.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ : (вариант: тавыш бирү формасы гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә)

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим яңгырады.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
_ _ _ _ _ _ Яклап
_ _ _ _ _ _ _ Каршы

## КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**

______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә))

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: "Әйе" -___.
"Юк» -____.

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**

______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә))

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

Тавыш бирү нәтиҗәләре: "Әйе" -___.
"Юк» -____.

**Рәислек итүче: йомгаклау карарының нәтиҗәсе гражданнар Җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча җирлекнең_ _ Уставы нигезендә рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка игълан ителәчәк).**

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ __________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Халык җыены секретаре _________ __________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл жирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы" нигезләмәгә

11 нчы номерлы кушымта

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ УЗДЫРЫЛГАН ЭТАПЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ҖЫЕННЫҢ ЙОМГАКЛАУ ПРОТОКОЛЫ**

_______________________________________
(Татарстан Республикасы торак пункты, муниципаль районы исеме)

«______» _________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут № ____

Гражданнарның беренче этабы _ _ _ _ __ _ 20-нче номерлы (рәислек итүче ФИО), 20-20-нче номерлы Гражданнарның икенче этабы беркетмәсе (рәислек итүче ФИО) һәм башкалар буенча, сорау - (үзе үк) буенча этаплап гражданнар җыеннары үткәрелде.)____________________________________________________________

1. Җыеннын үткәрелгән этапларының тавыш бирү формасы (ачык, яки ябык (яшерен) күрсәтелеп саны)_______
2. Гражданнар җыеннарының этаплап уздырыла торган беркетмәләре саны _______
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм аларның эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны __________;
4. Сайлау хокукына ия һәм гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны___________

**Хәл иттеләр: (карар эчтәлеге)**

- Гражданнар җыены этапларында кертелгән мәсьәләгә (ӘЙЕ) өчен бирелгән тавышларның гомуми саны _________;
- Кертелгән мәсьәләгә (КАРШЫ) бирелгән тавышларның гомуми саны) ________

**КАРАР: кабул ителде ( кабул ителмәде,сәбәпләрен күрсәтеп)**

Рәислек итүче (җирлек башлыгы): ______ ___________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Сәркәтип: _________ _______________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы” нигезләмәгә

12 нче номерлы кушымта

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫНЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ ПРОТОКОЛЫ**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге территорисенә керүче -------------торак пунктларда тавыш бирү нәтиҗәләре турында

«_____» _______ 2019 ел
Татарстан Республикасы----------- муниципаль районы ------җирлеге.......авылы

Катнашучы хисап комиссиясе әгъзалары :
ФИАи

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булып ,катшашкан гражданнар ______

Гражданнар Җыенының беренче этабы көн тәртибе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре :

«______________________________________________________________»

**Яклап__________тавыш**

**_Каршы__ _ тавыш_**

Хисап комиссиясе рәисе ФИАи

Хисап комиссиясе әгъзалары:

ФИАи

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы" нигезләмәгә

13 нче номерлы кушымта

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫНЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ ПРОТОКОЛЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге территорисенә керүче -------------торак пунктларда тавыш бирү нәтиҗәләре турында

«_____» _______ 2019 ел    № 2

Татарстан Республикасы --------- муниципаль районы ------җирлеге.......авылы

Катнашучы хисап комиссиясе әгъзалары :
ФИАи

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булып ,катшашкан гражданнар_____________

Гражданнар Җыенының икенче этабындагы көн тәртибе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре :

«_____________________________________________________________________»

**Яклап__________тавыш**

**Каршы___ _ _ тавыш_ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _**

Хисап комиссиясе рәисе    ФИАи

Хисап комиссиясе әгъзалары:

ФИАи

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл жирлеге
территорисенә керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе
турындагы" нигезләмәгә

14 нче номерлы кушымта

## ХИСАП КОМИССИЯСЕ ПРОТОКОЛЫ

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге территорисенә керүче торак пунктларда халык җыенының беренче, икенче этаплары нигезендә тавыш бирү нәтиҗәләре**

«___» ____________ 20__ ел ____________________________________
(торак пункт исеме)

Гражданнар Җыенының беренче, икенче (һ. б.) этаплары нәтиҗәләре
__________________________________________________________________________
(территориянең исеме
__________________________________________________________________________
муниципаль берәмлегенең яисә аның өлешенен)

Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү датасы һәм вакыты: ________________
______________ 20__ ел

Гражданнар җыеннарында тавыш биргәндә тавышларны санау нәтиҗәсендә (- ам):
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

**Хисап комиссиясе билгеләде:**

1. Халык җыенының үткәрелгән этаплары саны __________________________________________;
2. Гражданнар җыены этапларының үткәрелгән хисап комиссиясе беркетмәләренең тәкъдим ителгән саны ____________________;
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм җыен эшендә катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны__________;
4. Җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны ____________________;

5.Гражданнар җыены этапларында кертелгән мәсьәләгә (ӘЙЕ) өчен бирелгән тавышларның гомуми саны _________;

6. Кертелгән мәсьәләгә (КАРШЫ) бирелгән тавышларның гомуми саны)
_______

**Хәл иттеләр:**

1. Мәсьәлә буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга__________________, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә әлеге мәсьәлә буенча җыенны хәл итү карары____________________кабул ителгән дип санарга.

Хисап комиссиясе рәисе ______________________ _________________
(фамилиясе, инициаллары) (имза)

Хисап комиссиясе әгъзалары 1. __________________________ _________________
(фамилиясе, инициаллары) (имзалары)

2. __________________________

Беркетмә төзелде«___» _____________ 20___ ел